ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧЕРНЫШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район,
д.Чернышевка, ул. Клубная,1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧЕРНЫШЕВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Чернышевка авылы, Клуб ур., 1

тел./факс 8(84365) 73-5-05, e-mail:Chern.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**04 март 2020 г.** **№ 39**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Башкарма комитетының аерым Карарларын үз көчләрен югалткан дип тану турында**

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы» Федераль законы, Татарстан Республикасының 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турындагы» Законы нигезендә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча, Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге норматив хокукый актларын гамәлдәге законнар белән тәңгәлләштерү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 нче елның 10 нчы июлендәге 23 нче номерлы «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату-алулар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентын раслау турындагы» карарын;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 нче елның 10 нчы июлендәге 28 нче номерлы «Гражданнарга шәхси торак төзелеше өчен, торак пункт, бакчачылык, дача чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына аның крестьян (фермер) эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеген милеккә (арендага) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турындагы» карарын.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтындагы: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе О.А.Маланин

Чернышевка авыл җирлеге Советы
Совет Чернышевского сельского поселения
ИНН 1616006065